СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

06.07.2020 г.Зеленодольск № 503

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 76 номерлы Карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы законнар нигезендә, 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән Зеленодольск муниципаль районы Советы карар **кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 76 номерлы Карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль

вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәгә (алга таба Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Керемнәр, чыгымнар турында белешмәләр район Советы карары белән расланган исемлектә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда һәм форма буенча тапшырыла.»

2.Әлеге Карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **Э.Р. Кадникова**